РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Центральная, д.46, с.Бизяки, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423648

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк урам, 46 йорт, Бәзәкә авылы, Менделеевск районы, Татарстан Республикасы,423648

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 10 09.11..2024 ел

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең
Мари Тәкәше авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябре 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Мари Тәкәше авылы, Үзәк урам, 1 йортта урнашкан иҗтимагый үзәкне билгеләргә.

2. «2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Мари Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту. Мари Тәкәше авылына вак таш сатып алу, илтеп җиткерү, тигезләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Мари Тәкәше авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы ________________ И.И.Кәшәфетдинов
(имза) (имзаның аңлатмасы)